# Мәктәп хәбәрчесе

**№1 (№22) гыйнвар 2021 ел**

**Түбән Майна урта мәктәбе газите**

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

***/Мөхәррир сүзе/***

## *2021 – Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В ТАТАРСТАНЕ 2021
ТАТАРСТАНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Президент Рөстәм Миннеханов быелгы елның төп лозунгын ана телебезне олылау, аңа игътибарны арттыру максатынннан билгеләде. Максаты да хасиятсез генә барлыкка килмәгәндер. Туган телне саклау бүгенге көндә кешелек экологиясен саклауга тиң. Тел гади аралашу чарасы гына түгел, ул мең еллар буенча гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе дә, әдәп, әхлак та, туктаусыз язылып торган тарих та. Димәк, туган телебезне саклау бурыч кына түгел, яшәү рәвеше булырга тиеш кебек. Тик.....

Һәр кош тәренең сайрашуы үзенчә. Сандугач беркайчан да сыерчык булып сайрамый. Башка җан ияләре дә үз калебләренә тугры. Ә дәүләтсез һәм азсанлы халыкларның туган телләрен югалту дәрәҗәсенә җиткерүе –кемгәдер ярарга тырышып, балаларыбыз белән үз ана телләрендә сөйләшмәүдән. Бернича еллар элек авылга кунакка кайткан бала татарча өйрәнгән булса, бүгенге көндә кире нәтиҗә күрәбез. Бу очрак туган телебезне сансызлау кебек, ана сөте белән кергән күркәм гадәтләребезне әкренләп югалта баруыбыз булып чыга. Бу - милли горурлык һәм узаңның да юкка чыга баруыдыр.

Мәктәбебез бу елның күрсәтмәсенә таянып, билгеле бер эшләрне, укучылар белән берлектә башкара башлады. Иң беренче эш итеп, 21-нче гыйнварда туган телләр елын тантаналы рәвештә ачып җибәрдек. Ачылу тантанасы ütәчәк зал диварлары олпат язучыларның тел турында әйткән тирән фикерләре белән бизәлде. Китаплардан һәм халкыбызның милли ашларыннан күргәзмә ясап өстәлгә тезелде. Бу эшкә укучылар да, әти-әниләр дә бик тә җаваплы караган!!! Өстәлләр милли ризыкларыбыздан сыгылып тора иде. Моның өчен укучылар аеруча шат һәм канәгать иделәр. Бәйрәм өлеше башлангыч сыйныфларның телгә, халыклар бердәмлегенә багышланган концерты белән башланды. Иске Әдәм авылы китапханәчесе Таһирова Равия апа балаларга милли киемнәр турында сөйләде. Бәйрәмнең йомгаклау өлешендә телгә багышланган уеннар да булды.

Аңлашыла, телгә мәхәббәтне мондый бәйрәм чаралары белән генә дә уятып булмас. Шулай да, укучылар өчен



бу юнәлеш эзсез узмас диеп уйлыйбыз. Телебезнең мәңгелек тарихы бар, гореф-гадәтләребез шул телгә нигезләнгән. “Әни” сүзе белән телебез ачылган. Хәреф танып, белем иленә керүебез туган телебездән башланган. Милләтебез һәм ана телебезнең киләчәге синең кулда, кадерле укучым. Ана телендә аралашудан тәм табарга, күп итеп әдәби әсәрләр һәм татарча китаплар укырга, сөйләм телеңне чистартырга чакырабыз. Туган халкыбызның лаеклы уллары һәм кызлары булып үсик!

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина***

## *Туган телем белән горурланам!*

Мин үз телем белән, милләтем татар булуы белән горурланам. Чөнки тарихта татарларның батыр, бил бирмәс булуларын беләм. Татарлар милләтне, телебезне, динебезне яклап көрәшкәннәр. Көчләп чукындырганда да бирешмичә, динебезне сатмаганнар. Безнең буынга гореф-гадәтләрне, милли йолаларыбызны, телебезне саклап китереп җиткергәннәр.

Мин татар мәктәбендә белем алам. Гаиләмдә шул телдә аралашам. Әнием, әтием, әбием миңа шул телдә “улым” диеп эндәшә. Ул безнең көндәлек тормышыбыз. Без аның шулкадәр кирәк тел диеп тә белмибез. Күз алдына гына китереп карыйк әле: телебез булмаса нишләр идек? Ул турыда уйлавы да кыен.

Шуңа күрә, дуслар, булганның кадерен белик, тормышыбыз өчен мөһим булган телебезне саклау дәрәҗәсенә калдырмыйк. Туган телебез – татар теле булган, бар, һәм киләчәктә дә булсын ул.

***Илсур Морадимов, VIII сыйныф укучысы***

***/Безнең спорт/***

## *Көрәш җиңүләрдән генә тормый*

“Шәһәр баласына рәхәт инде, авылныкы гына бер җиргә дә бара алмый, түгәрәкләр эшләми”, – дип әйтүләр артта калды. Чөнки хәзер бар җирдә дә үзеңә хуш килерлек шөгыль табарга мөмкин. Вакытны кызыклы гына түгел, ә файдалы итеп үткәрү өчен мәнә дигән спорт төре булган көрәш түгәрәген сайладым мин. Аның белән шөгыльләнгән егетләр үзендә ихтыяр көчен туплыйлар, ярышларда катнашып җиңү яулагач, үзләренә зур максат куялар. Мин һәм иптәшләрем бернича ел рәттән **тренерыбыз Илһам абый Камалов** җитәкчелегендә төрле ярышларда катнашып киләбез. Җиңелгән дә, җиңгән вакытлар да булды. Ярыш булгач, әлбәттә, җиңелү дә булмый калмый. Мондый вакытта һәрберебезнең характерлары ныгый, һәм үз өстеңдә тагын да ныграк эшләргә теләк туа. “Нинди генә авырлыклар, хәтта күз яшьләре булса да, бу спорт төренә кереп китсәң, кире чыгып булмый”, – дип әйтә көрәшчеләр. Көндәшеңнең беленә сөлге урап, аны күтәреп, аркасына салу – үзе ни тора бит.



Узган айда Зәй шәһәрендә уздырылган **билбау көрәше буенча Россия чемпионатында** без, Майнаның көрәшче егетләре, үз көчләребезне сынаштык. Безнең егетләр арасыннан **Нурматов Халит Әнвәр улы** үз авырлыгында **өченче урынны** яулап кайтты. Безгә бу юлы уңыш елмаймаса да, иптәшебез өчен бик шатландык. Ә ай ахырында Базарлы Матакта узган **билбау көрәше буенча Республика турнирында** Халит **беренче**, ә мин **өченче урыннарны** алдык. Алдагы ярышларда да җиңүләргә өмет итәбез.

***Ильяс Хәбибрахманов, IX сыйныф укучысы***

## *Шахматлы каникул*

Кыш. Каникул. Шахмат. Мәктәбебез шахматчысы Гафиятуллин Фаил һәм район шахматчылары, кайткан кунакларның ялларын рус шагыйре Александр Блок шигырендәге кебек дәвам итәсе килә. 6-нчы гыйнвар көнне Аксубай районы Кече Сөнчәле авылы клубында атказанган фән эшлеклесе академик С.А.Абруковның тууына 100 ел уңаеннан шахмат турниры уздырылды. Шахматчылар төрле яшьтә һәм категориядә иделәр. Монда бәяләү дә яшь үзенчәлекләренә бүленмәде, гомуми нәтиҗә ясалды.



Турнир мавыктыргыч һәм кызу үтте. 1-нче урынга Самара өлкәсеннән килгән тәҗрибәле шахматчы, 2-нче урынга күп еллар шахмат уйнаучы Норлат чемпионы, 3-нче урынга **Фаил Гафиятуллин** лаек булды. Җиңүчеләр кыйммәтле бүләкләр һәм грамоталар белән бүләкләнде. Барлык катнашучыларга да рәхмәт грамоталары тапшырылды.

***Рузилә Хәйруллина, IV сыйныф җитәкчесе***

***/Күңелле тәнәфес/***

**Беренче иҗектә “О”, икенчесендә “Ы” хәрефе булган 20 сүз яз.**

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы |
| | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы |
| | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы |
| | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы |
| | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы | | | | о | | ы |

**БЕР СҮЗ БЕЛӘН ӘЙТ:**

Табан ялтырату ______________

Ефәктәй булу ______________

Дуамал баштан ______________

Балавыз сыгу ______________

Баш күккә тию ______________

Авызга су кабу ______________

Чәчләр үрә тору ______________

Түшәмгә төкереп яту ______________

Җир тишегенә керерлек булу ______________

***/Котлыйбыз!/***




Гыйнвар аенда туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз **Закирова Ләйсәнне** (18.01.), **Җамалетдинова Инзиләне** (01.01.), **Хәбибрахманова Мәрьямне** (07.01.), **Камалов Илдусны** (01.01.) чын күңелдән котлап, сәламәтлек, озын гомер, укуларында уңышлар телибез.

Укытучылар **Зарипов Фәнил** ( 02.01) һәм **Хөснулли Фәнис** (01.01) абыйларны, тәрбияче **Бәширова Альмира** (06.01), **Сәгъдиева Рәмзия** (01.01.) апаларны гомер бәйрәмнәре белән ихластан котлап, сәламәтлек, эшләрендә уңышлар, гаилә бәхете теләп калабыз.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәмматова
Зөлфирә Сафиуллина

## Телебезнең байлыгы

Телебезнең байлыгы
Сүзләреннән җыела
Сүз гади дә, бөек тә
Ул үзе бер могҗиза.

Телебезнең байлыгы
Сүзләрендә чагыла.
Аларга шатлыклары да,
Сагышлары да сыя.

Телебезнең байлыгы
Сүзләреннән тезелә.
Ул әти дә, әни дә
Укыган белемем дә.

Телебезнең байлыгы
Ул милләтнең асылы.
Чөнки тупланган аңа
Гасырларның акылы.

***Айсылу Галиуллина,***
***XI сыйныф укучысы***

*/Укучылар иҗаты/*

## Кышкы урманда

Кышкы урманга бармый калу – безнең өчен кышның тәмен тоймый калу белән бердер. Ел саен кышкы каникулның бер көнендә Чәчәби тавына барып шуып кайту, чишмәсеннән су эчү, куаклыкка кереп бәрәңге пешерү белән гадәткә кергән. Кышкы табигать ел саен бер төсле кебек тоелса да, ничектер барган саен бер үзенчәлек табасың. Быел монда ничектер тынычрак та, кыргый җәнлекләр эзе дә сирәгрәк күренде. *Бу турыда Ак китаптан Чәчәби кунакларының азрак булуын чамаладык.*



Рәхәтләнеп тауда чаңгы шудык. Кайберләребез бәрәңге пешерә торды. Учак кызган арада “тау патшасы”н уйнадык. Бу уенда студентлар Илнар абый белән Илсур абыйны җиңдек. Көнебезне матур итеп уйнап үткәрдек. Тәмле итеп учакта пешкән бәрәңге ашап кайттык. Телефоннардан бераз аерылып, сәламәтлегебез файдасы өчен бер үткәрдек.

***Илдус Камалов, IX сыйныф укучысы***

## Тел турында уйланулар

Туган тел – ул без үз тирәбездә кечкенәдән ишетеп үскән тел. Әниләребез дә, якыннарыбыз да бу тел белән безнең янда аралаша. Безнең тирәдә һәрвакыт шул тел яңгырап тора. Шуңа күрә якын да, иң аңлаешлы тел дә инде ул.

Мин, милләтем нинди генә булса да, туган телемне бүген татар теле дип атыйм. Чөнки мин шушы тел белән балалар бакчасында йөрдем, шул телдә белем алам. Дусларым белән дә татар телендә аралашам. Яшәвем дә чын татар авылында. Күршеләрем белән дә татар телендә аралашабыз. Телефонда, башка уеннарда, социаль челтәрләрдә башка тел белән вакыт уздырсак та, белгән телләр беркайчан комачауламый.

Дусларым, телләр күбрәк белгән саен кызыклырак була бара дөнья. Моны барыбыз да аңлый. Туган телем-йөрәккә якын татар теле, һәм мин аның җылысын тоеп яшим. Телебезне саклау өчен кулдан килгәннең барысын да эшлик, чөнки бу безнең туган телебез!

***Карина Шичкина. VIII сыйныф укучысы***



## Гөлшат апа бүләге

Кышкы каникулдан килгәч, без мәктәпнең спорт залына яңа гына спорт инвентарена тап булдык. Бу зур бүләк безгә әтиемнең сеңелесе Гөлшат апа тарафыннан, тормыш иптәше Фазыл абый истәлеге итеп бирелде.

Фазыл абый безнең авыл өчен мәңге онытылмаслык эз калдырган кеше. Кызганычка каршы 2018 елда ул безне калдырып якты дөньядан китеп барды. Әмма аның бу дөньяда калдырган игелекле эшләре бик күп булды. Безнең авылда гына да ул мәчеткә, клубны ремонтлауга, һәйкәл төзүгә, зират коймасын тотуга зур ярдәмнәр күрсәтте. Авылыбыз уртасындагы мәктәп бинасы Фазыл абыйга куелган һәйкәл кебек тора. Чөнки бу бинаны ул җитәкләгән оешма төзеде.

Гөлшат апабыз 1980-1988 елларда безнең мәктәптә укый. Аннан соң укуын Иске Әдәм мәктәбендә дәвам итә. Һәр яктан алдынгы укучы булып, мәктәпне „5" ле билгеләренә тәмамлый. Фармацевт белгечлеген алып, хезмәт юлын аптекада эшләүгә багышлый. Гөлшат апа бик эшчән, тырыш, һәркем өчен мәрхәмәтле кеше. Алар Фазыл абый белән бик күпләргә ярдәм итеп, шатлык китереп яшәделәр.

Гөлшат апа тапшырган бүләк файдага булсын, егетләребез аңарда шөгыльләнеп чыныксыннар, көчләрен арттырсыннар иде. Шундый зур бүләк өчен Фазыл абыйның рухы шат, урыны җәннәт бакчасында булсын.

***Сара Насыйрова, X сыйныф укучысы***

*/Мәктәп тормышы/*



## ЮИД өчен яңа формалар

Мәктәпнең ЮИД командасына кагылышлы вакыйгалардан, узган чирек ахырында башлангыч сыйныф укучылары өчен юл хәрәкәте иминлегенә багышланган ачык дәрес үткәрелгән иде. Дәрес ахырында 1-нче сыйныф укучылары юл хәрәкәте иминлеге инспекторлары сафларына кабул ителеп, аларга ЮИД бүләкләре тапшырылды. Инде менә бу чиректә мәктәпнең ЮИД отряды өчен яңа формалар кайтты. 23-нче гыйнвар көнне линейкада алар яшь инспекторларга тапшырылды.

## Техникум вәкилләре белән очрашу

25 нче гыйнвар көнне мәктәпкә Аксубай универсаль технологияләр техникумыннан килгән вәкилләр чыгарылыш сыйныф укучылары белән очрашты. Алар район үзәгендә генә дә төрле һөнәр алу мөмкинлекләре турында, соңгы елларда техникумда булган зур үзгәрешләр, тулай торакның уңайлыклары һәм укучылар өчен тудырылган шартлар турында сөйләделәр.

## Коррупциягә каршы көрәш

26 нчы гыйнварда югары сыйныф укучылары өчен “Коррупция һәм аңа каршы көрәш” темасына сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Дәресләрдә түбәндәге мәсьәләләр яктыртылды:

- коррупция турында аңлатма бирү, аның билгеләре белән танышу;
- коррупцияне тормыш шартларында таный белү, ул китергән зыянга үз фикереңне белдерә белү;
- коррупцияле гамәлләр өчен җинаять җаваплылыгы.

## “Батырлык дәресе”


27 нче гыйнвар көнне укучылар өчен “Батырлык дәресе” үткәрелде. Бу чараның максаты батырлык төшенчәсен аңлату, сугышның кырыс чынбарлыгын, халкыбызның сугыш кырларындагы батырлыгын, патриотизмын һәм милли горурлыгын күрсәтү иде.

***Хәйруллина Рузилә, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***

*/Чал тарихта эзле без/*


## Элеккеге математика дәреслекләреннән бер үрнәк

Моннан өч еллар элек, мәчеткә тапшырылган гарәп язулы иске китаплар арасыннан бер хисап (арифметика) дәреслеге табылган иде. Хәзерге вакытта бу китап мәктәптәге музей күргәзмәсендә саклана. Аңа кадәр табылган математика дәреслекләре турында 2017 нче елда, мәктәптә уздырылган конференция материаллары җыентыгында, мәкалә бастырылган иде. Бу китап аннан соң гына табылып өйрәнелгәнгә, аның эчтәлеге турында хәзер бирергә булдык.




Карала торган китап хисап гыйлеменә кереш рәвешендә язылган. Титул һәм беренче битләре сакланмаганлыктан, исемен, авторын һәм басылган елын ачыклап булмады. Тел үзенчәлекләре һәм мәсьәлә текстларыннан чыгып исәпләгәндә, китап 1890 елларда басылган һәм кулланылган кадими мәктәп дәреслеге булып тора.

Китапның башында бердән миллиардка кадәрге натураль (бөтен) саннарның язылышы һәм укылышы бирелә. Төп өлештә дүрт арифметик гамәл (әгъмәл әрбага) – **кушу** (җәмг), **алу** (тарх), **тапкырлау** (дарб) һәм **бүлүне** (тәкъсим) өйрәнү карала. Барлык гамәлләр дә аслап эшләү ысулы белән өйрәтелә. Шулардан соң кушу һәм алу гамәленең дөреслеген тикшерү ысуллары (мизан) аңлатыла. Сумманың дөреслеге астан өскә таба кушып, ягъни кушылучыларның урынын алыштырып тикшерелә. Аерманың дөреслеген тикшерү өчен, аермага алынучыны кушу алымыннан гыйбарәт. Һәр гамәлне өйрәтү тәмамлангач, тема ахырында “имтихан зиһен” биремнәреннән 3-5 мәсьәлә эшләү каралган. Әлбәттә, укучылар тиешле дәрәҗәдә күнекмә алсын өчен, моның кадәр биремнәр эшләү генә җитми. Димәк, бу китапка өстәмә рәвештә тагын мәсьәләләр җыентыгы тибындагы уку әсбабы кулланылган булырга тиеш. Безнең тупланмада андый китаплар да бар.




Безнең карамактагы башка хисап дәреслекләреннән аермалы буларак, бу китапта 1дән 9га кадәрге берәмлекләрне кушу һәм тапкырлау җәдвәлләре (таблицалары) китерелә. Шушы таблицалар белән эшли алган укучыларга **БҮЛӘК** бирeләчәк.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***